РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28»062021 г. №502

2021 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең чик күрсәткечләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының “Ютазы муниципаль районы буенча 2021 елның 1 кварталына торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 44 номерлы карары нигезендә, Башкарма комитет карар бирә:

1. 2021 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең түбәндәге чик күрсәткечләрен, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына найм шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы буенча билгеләргә (1 нче кушымта)

2.Торак сәясәте бүлегенә гражданнарны социаль файдаланудагы торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә

куйганда 1 нче кушымтада күрсәтелгән керемнең максималь күләмен кулланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче С.П. Самонина

Н.А. Әбилтарова
2-76-81

Кушымта №1
ТР Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
карарына
"_28_"_06_2021 ел
№502

**2021 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз**

**яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле**
**мөлкәт хакының чик күрсәткечләре**

| Гаилә әгъзалары саны (ИБ) | Торак урын бирү нормасы буенча базар бәясенең исәп күрсәткече (ТБ) | Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача тулаем керемнең чик күрсәткече |
|---|---|---|
| 1 | 811 899 | 18 935,8 |
| 2 | 1 033 326 | 12 050,2 |
| 3 | 1 328 562 | 10 328,9 |
| 4 | 1 771 416 | 10 328,9 |
| 5 | 2 214 270 | 10 328,9 |
| 6 | 2 657 124 | 10 328,9 |
| 7 | 3 099 978 | 10 328,9 |
| 8 | 3 542 832 | 10 328,9 |
| 9 | 3 985 686 | 10 328,9 |
| 10 | 4 428 540 | 10 328,9 |